**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**2022 елның 11 ноябре** **№ 28**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске-Юмья торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске-Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья торак пункты гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы:

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

«- Иске Юмья авылында суүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын, су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, су башнясы өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге
башлыгы С.В. Тимофеев